ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТУКАЙ МУНИЦПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯҢА БҮЛӘК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

**КАРАР**

"25" октябрь 2024 ел Яңа Бүләк авылы №22

**"Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Яңа Бүләк авыл җирлегенең Яңа Бүләк авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында"**

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Тукай муниципаль районы "Яңа Бүләк авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставының нигезендә Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Яңа Бүләк авыл җирлегенең Советы 30.11.2019 ел, № 43/1 «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Яңа Бүләк авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында" нигезләмәне раслау хакында» карары белән

**КАРАР БИРӘМ:**

1. Тукай муниципаль районы Яңа Бүләк авыл җирлегенең Яңа Бүләк авылында 2024 елның 7 ноябрендә 14.00 сәгатькә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләргә.
2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"Яңа Бүләк авыл җирлегенең Яңа Бүләк авылы территориясендә 2025 елда балигъ булган, Яңа Бүләк авыл җирлегенең Яңа Бүләк авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр кешегә 500 (биш йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I һәм II группа инвалидларга һәм Бөек Ватан сугышы ветераннарына, ялгыз карт гражданнарга һәм көндезге формада укучы студентларга, күп балалы гаиләләргә бер тапкыр түләүне киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 250 (ике йөз илле) сум күләмендә билгеләргә, РФ Хәрби Көчләренә өлешчә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарны, аларның гаилә әгъзаларын үзара салым буенча взнослар түләүдән азат итәргә, аларның суммасы түбәндәге мәсьәләләрне:

- Һәйкәлләр (Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) булмаган) төзү, ремонтлау һәм янәшә территорияне төзекләндерү( Яңа Бүләк авылында тыл ветераннарына һәйкәл кую);

хәл итүгә юнәлдерүгә килешәсезме

"ӘЙЕ" "ЮК".

- Татарстан Республикасы, Тукай районы, Яңа Бүләк авылы, Г.Тукай урамы, 38 йорт адресы буенча гражданнар җыенын үткәрергә.

3. Тукай муниципаль районы Яңа Бүләк авыл җирлеге башкарма комитетын Гражданнар җыенын оештыручы итеп билгеләргә.
4. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.
5. Әлеге карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында "авыл җирлекләре" бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.
7. Әлеге карар халыкка җиткерелгән көннән үз көченә керә.

Яңа Бүләк авыл җирлеге Башлыгы М.С. Сагетдинов